**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** | **РЕШЕНИЕ**

**17 апрель 2019 ел** | **№ 122**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 107 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта “бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллланучылар ширкәтләре” сүзләрен бетерергә;

2) 10 пунктны бетерергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында: ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет ур., 13 йорт, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Никитенко Р. Р. йөкләргә.

Совет рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин